Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Түбән Мактама бистә Советы

# КАРАРЫ

26 апрель 2024 ел №110

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама бистә Советының 2021 елның 28 октябрендәге 38 номерлы «Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистә» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы хакындагы нигезләмәне раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2024 елның 30 январендәге 02-08-01/36 номерлы протестын караганнан соң

Түбән Мактама бистә Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама бистә Советының 2021 елның 28 октябрендәге 38 номерлы «Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистә» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы хакындагы нигезләмәне раслау турында»гы карарына (Әлмәт муниципаль районы бистә Советының 2022 елның 25 февралендәге 46 номерлы, 2022 елның 13 июлендәге 58 номерлы, 2023 елның 19 маендагы 82 номерлы, 2023 елның 30 октябрендәге 96 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 бүлек 8 статья 11 пункт 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) Бюджет йөкләмәләрен яки бюджет ассигнованиеләренең җиткерелгән лимитлары чикләрендә бюджет йөкләмәләрен кабул итә һәм үти, элек кабул ителгән бюджет йөкләмәләренә үзгәрешләр кертә;»

1.2. 12 статья 1 бүлекнең өченче абзацы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Башкарма комитетның резерв фонды күләме җирлек бюджеты турындагы карар нигезендә җирлек Советы белән билгеләнә.».

2. 1 бүлек 19.1 статья 3 пункт, 19.2 статья 3 пунктның 2024 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 1 гыйнварына кадәр (бюджет турында карар нигезендә муниципаль гарантияләр бирү өлешендә) гамәлдә булуын туктатып торырга.

3. Әлеге карарны Әлмәт районы Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе һәм Тихоновка авылы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында игълан итәргә, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның 2 пункты рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистә башлыгына йөкләргә.

Түбән Мактама шәһәр
тибындагы бистә башлыгы Р.А. Бәдретдинов